**МИНИСТЕРСТВО ПРОСВЕЩЕНИЯ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ**

**Министерство образования и науки Республики Татарстан**

**Муслюмовский муниципальный район Республики Татарстан**

**Баланнинская ООШ**

| РАССМОТРЕНО | СОГЛАСОВАНО | |
|---|---|---|
| ШМО учителей начальных классов | Заместитель директора по УВР Ахметова С.Ф. | ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ<br>СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП<br>Сертификат: 00A3F5BA0A9DE06A6D37E18410DFF14482<br>Владелец: Сафин Фатих Нуруллович<br>Действителен с 05.07.2023 до 27.09.2024 |
| Газымова Г.Р.<br>Протокол № 1 от «28» августа 2023 г. | Протокол № 1 от «29» августа 2023 г. | |

**РАБОЧАЯ ПРОГРАММА**

**учебного предмета «Литературное чтение на родном (татарском) языке»**

для обучающихся 1– 4 классов

**Баланны 2023**



Документ создан в электронной форме. № 41 от 23.05.2024. Исполнитель: Сафин Ф.Н.
Страница 1 из 41. Страница создана: 23.05.2024 10:28
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

## УКЫТУНЫҢ БЕРЕНЧЕ ЕЛЫ

### ПЛАНЛАШТЫРЫЛГАН ПРЕДМЕТ НӘТИҖӘЛӘРЕ

***“Грамотага өйрәтү” нең әлифба чорында***

***Укучы өйрәнәчәк:***

– авазларны сузык һәм тартык авазларга бүләргә;
– тартык авазларны калын һәм нечкә, яңгырау һәм саңгырау, ә сузыкларны басымлы һәм басымсыз авазларга бүләргә;
– сүзләрне иҗекләргә бүләргә, басым куярга;
– предметны, аның билгесен, эшен белдергән һәм ярдәмче сүзләрне(кисәкчә, бәйлек) табарга;
– телдән җөмлә һәм текстны тел берәмлекләренә бүләргә;
– язма һәм басма язуны аерырга;
– басма хәрефләрнең формасын белергә ;
– авазларны дөрес әйтергә, аларның урнашу эзлеклелеген белергә, авазларга характеристика бирергә;
– анализ вакытында авазларның саңгырау һәм яңгырау булуын билгеләргә, сүздәге басымлы иҗекне табарга;
– җөмләгә схема ясый, схемасы буенча җөмлә төзергә;
– шаблоннар ярдәмендә һәр хәрефне төзи белергә, анализларга;
– парта артында дөрес утырырга;
– сүзләрне дөрес итеп укырга.;
- укылган әсәрнең кыскача эчтәлеген сөйли белергә.

***Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:***

– элементар образлы күзаллау дәрәҗәсендә тел берәмлекләре: сүз, җөмлә,текстны аңлый, шулай ук татар алфавитының басма һәм язма хәрефләр системасын атый һәм формалары буенча аера белергә;.

– рәсем, график модель яки тиешле фишкалар кулланып, дәрестә тудырылган тел ситуацияләре буенча 2 — 4 сүздән торган җөмләләр һәм 3 — 4 җөмләдән торган хикәя төзергә;

– парта артында дөрес утыра һәм язма әсбаплардан дөрес файдалана б*елергә.*

***“Әдәби уку” чорында***

***Укучы өйрәнәчәк:***

– кычкырып укыганда, индивидуаль темп белән йөгерек, иҗекләрне өзми сүзләп укырга;
– ишеткән яисә сыйныфта укыган кыска әсәрнең эчтәлеген аңларга, төп мәгънәсен әйтә белергә;
– текстның маркирланган өлешен эчтән укып, эчтәлеген аңларга;
– төрле авторның 3—4 әсәрен яттан укырга.
– проза әсәрләрен шигъри әсәрләрдән аера белергә;
– фольклорның кече жанрларын (табышмак, санамыш, тизәйткеч, әйтеш, уйдырмалар) аера белергә;
– әдәби текстта кабатлаулар, җөмлә төрләрен, тыныш билгеләрен, ритм һәм рифмаларны таба белергә.



Документ создан в электронной форме. № 41 от 23.05.2024. Исполнитель: Сафин Ф.Н.
Страница 2 из 41. Страница создана: 23.05.2024 10:28
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

***Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:***

– дәреслекнең «Эчтәлек» битендә кирәкле әсәрне таба белергә;

– укылган әсәр буенча сораулар төзи, эчтәлеген сөйли һәм тексттан файдаланып сорауларга җавап бирә белергә;

– әкиятләрнең сюжет-композиция үзенчәлекләрен аерырга (чылбыр әкиятләрне аптыраткыч әкиятләрдән);

– кече фольклор әсәрләрендә төрлелекне тоемлый белергә (хикәя-әкият, бишек җырлары-әйтешләр);

– текстны укыганда дөрес интонация, уку темпын сайлап, паузалар белән укый белергә;

– әдәби әсәрләрне укыганда, текст кырындагы маркировкага нигезләнеп (төсле полоскалар), рольләргә бүленеп, чылбыр рәвешендә укый белергә;

– әсәргә ясалган иллюстрациягә туры килгән өлешне тексттан таба белергә;

– кече фольклор жанры әсәрләрен практик өйрәнергә (табышмак, санамыш, тизәйткеч, әйтешләр, уйдырмалар), аларны мимика, хәрәкәтләр белән бирә белергә;

– «Музей йорты» бүлегендә (рәссам Фәридә Ризаева күргәзмәсе), иллюстрацияләрне табып, дәреслекнең кайсы текстына туры килүен ачыкларга, текстның иллюстрация белән ни дәрәҗәдә туры килүен билгеләргә.

## УКЫТУНЫҢ ИКЕНЧЕ ЕЛЫ

### УКУ ПРЕДМЕТЫНЫҢ ПЛАНЛАШТЫРЫЛГАН НӘТИҖӘЛӘРЕ

***Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр:***

- үз эшчәнлегенең нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ формалаштыру;
- дәреслек геройларына, күршеңә ярдәм итүдә танып-белү инициативасын күрсәтү;
- үз мөмкинлекләреңне бәяләү, тормыш тәҗрибәсен куллану;
- дәрестә үзенең белем һәм күнекмәләрен куллану;
- үз фикереңне әйтә белү;
- иҗади эшчәнлеккә омтылыш булдыру;
- үз уңышларың-уңышсызлыкларың сәбәпләре турында фикер йөртү;
- кече яшьтәге мәктәп баласы үзе тел берәмлекләрен танып, таныш һәм таныш булмаганнарга бүлә белү;
- биремнәр системасында ориентлашырга өйрәнү.

***Метапредмет нәтиҗәләре:***

Танып белү универсаль уку гамәлләре:

-үзенә кирәкле информацияне таба белү; анализлый һәм информацияне бәяли белү;

-логик фикерләү чылбырын төзү;

-тәкъдим ителгән план ярдәмендә предмет, күренешләрне сурәтләү;

-мәгълүмат җиткерүче символларны уку;

-тормыш тәҗрибәсен кулланып, ситуациянең моделе буенча текст төзү;

-тәҗрибә куллану аша нәтиҗә чыгару;

-материаль объектлар (фишкалар) кулланып биремнәр үтәү;



Документ создан в электронной форме. № 41 от 23.05.2024. Исполнитель: Сафин Ф.Н.
Страница 3 из 41. Страница создана: 23.05.2024 10:28
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

-анализ, гомумиләштерү нигезендә нәтиҗә чыгару

Регулятив (көйләгеч) универсаль уку гамәлләре

-көч һәм энергия туплау, конфликтларны һәм каршылыкларны чишү максатында ихтыяр көчен үстерү;

-белгәнне һәм белмәгәнне аера белү;

-үз эшчәнлегеңне контрольгә алу, рәсемнәр ярдәмендә биремне үтәүнең дөреслеген тикшерү;

-эшләнәчәк эшкә мөстәкыйль максат куя белү;

-үз-үзеңне ихтыяр буенча көйләү;

-бәяләү нәтиҗәсен шартлы символик формада чагылдыру;

-дәрестә өйрәнелгән материалның фәнне өйрәнүдәге, тормыштагы әһәмиятен ачыклау;

-тормыш тәҗрибәсен куллану;

-үтәлгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү, уңышлылыгына бәя бирү;

-укучылар тарафыннан белгән яки әлегәчә белмәгән күнекмәләрне үзара бәйләү.

Коммуникатив универсаль уку гамәлләре

-тыңлаучыларга аңлаешлы сөйләм төзү;

-күзаллау, фаразлау; логик фикер йөртү осталыгы; күршең белән хезмәттәшлек итү; фикерләү сәләтен үстерү, карарлар кабул итү һәм аны тормышка ашыру; үз фикереңне тулы, төгәл һәм ачык, аңлаешлы итеп әйтү, аны яклау;

җитмәгән мәгълүматны башкалардан сорашып белү; иптәшеңнең үз-үзен тотышы белән идарә итү.

***Предмет нәтиҗәләре:***

-аерым төр һәм жанрга караган әсәрләрне аңлап укый һәм кабул итә, эчтәлеген кабатлап (аерым очракларда текстны яттан) сөйли, кирәк чакта тексттан өзекләр китерә алуга ирешү;

-укыган әдәби әсәрнең эчтәлеген, темасын, проблемасын, идеясен билгели, геройларын һәм әдәби дөньясын бәяли алуына, аның нинди төр һәм жанрга каравын аеруына ирешү;

-укучының классик әдипләрнең тормыш һәм иҗат юлларының төп фактларын белүе;

-әдәби текстның мәгънәви өлешләрен аерып чыгарып, укыган буенча тезислар һәм план төзү, геройларга характеристика бирү,сюжет, композиция үзенчәлекләрен, махсус сурәтләү чараларының ролен билгеләү күнекмәсе булдыру;

-укыган әсәр буенча фикер алышуда катнашырга, оппонентларның фикерен исәпкә алып, үз карашларын расларга һәм дәлилләргә, әдәбият белеме төшенчәләренә мөрәҗәгать итәргә өйрәтү.

-укучының  җаваплылык хисен активлаштыру;

-укуга һәм хезмәткә уңай мөнәсәбәт булдыру;

-баланың үзаңын үстерү, милләтне, ватанны яратырга өйрәтү, горурлык һәм гражданлык хисләре тәрбияләү;

-әхлак нормаларын, җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләрен төшендерү;

-төрле чыганаклардан (сүзлекләр, энциклопедияләр, интернет-ресурслар һ.б.) танып-белү һәм коммуникатив ихтыяҗларны канәгатьләндерерлек мәгълүматлар табарга күнектерү.

-укучыда әдәби әсәрне аңлап укырлык, мөстәкыйль үзләштерерлек күнекмәләр булдыру, әдәбиятка мәхәббәт тәрбияләү;

-сүз сәнгатен халыкның яшәү рәвешен, рухи кыйммәтләрен саклап калган һәм беркетә килгән хәзинә буларак кабул итәргә өйрәтү;



Документ создан в электронной форме. № 41 от 23.05.2024. Исполнитель: Сафин Ф.Н.
Страница 4 из 41. Страница создана: 23.05.2024 10:28
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

-язу һәм сөйләм осталыгын үстерү, мәсьәләне аңлый, гипотеза куя, материалны төркемли, үз фикерен дәлилли, кирәк икән – үзгәртә-төгәлләштерә, нәтиҗәләр чыгара, материалны гомумиләштерә белергә, үз хисләреңне сүзләр ярдәмендә аңлата алырга һәм бер үк вакытта башкалар белән бергәләп эшләргә күнектерү;

-баланың үз эшчәнлеген һәм әйләнә-тирәдәге тормышны мөстәкыйль бәяли белүенә, мөстәкыйль карарлар кабул итә һәм аларны җиренә җиткереп үти алуына ирешү;

-төрле чыганаклар белән эшләргә, аларны табарга, мөстәкыйль рәвештә кулланырга, төркемләргә, чагыштырырга, анализларга һәм бәяләргә өйрәтү.

## УКЫТУНЫҢ ӨЧЕНЧЕ ЕЛЫ

### ПЛАНЛАШТЫРЫЛГАН ПРЕДМЕТ НӘТИҖӘЛӘРЕ

***Укучылар өйрәнәчәк:***

-фольклор жанрларын аеру: хайваннар турындагы, тылсымлы әкиятләрне өйрәнү, мәсәл, хикәя турында күзаллау, халык иҗаты әсәрләре һәм автор әсәрләрен төркемли белү;

-әсәр геройларын характерлый белү, авторның үз героена мөнәсәбәтен күрсәтү, геройларга чагыштырмача характеристика бирү;

-халык иҗаты әсәрләре һәм автор әсәрләрен төркемли белү;

-әсәр геройларын характерлый белү, авторның үз героена мөнәсәбәтен күрсәтү, геройларга чагыштырмача характеристика бирүтөрле авторларның 6-8 шигырен яттан сөйләү:

-кыска күләмле әсәрләрнең эчтәлеген сөйләү;

-укылган әсәрдән чагыштыру, җанландыру, контрастны таба белү;

-сүзлекләрдән файдалану, тематик сүзлекләр төзү;

-аерым әсәрләргә аннотация төзү;

-элементы буенча китапта ориентлашырга өйрәтү;

әсәрнең сүзләрен дөрес әйтеп кычкырып һәм эчтән укый белү;

-әсәрнең темасын, төп мәгънәсен ачыклау, мәгънәви кисәкләргә бүлү, алар арасындагы бәйләнешләрне, төп фикерне билгеләү һәм аны үз сүзләрең белән әйтеп бирү.

***Укучылар өйрәнергә мөмкинлек алачак:***

-4-5 татар, рус, чит ил классикларының исемен, аларның әсәрләрен;

-1-2 балалар журналы һәм газетасының исемен, алардагы рубрикаларны;

-4-5 хәзерге заман язучысы яки шагыйренең исемен, алар язган әсәрләрне һәм эчтәлеген;

-үз илең, халкың һәм тарихың белән горурлану хисләре формалаштырырга, һөнәрләр дөньясы белән танышырга, җәмәгать урыннарында, мәктәптә үз-үзеңне тотуның әхлакый кагыйдәләрен үзләштерергә;

- уку эшчәнлеге һәм аның мотивлары арасында элемтә урнаштырырга;

- әдәби мәдәният нигезендә матурлыкны күрә белү һәм эстетик хисләр формалаштырырга;

-белем бирү учреждениесенә унай караш, татар теле фәнен өйрәнүнең кирәклеген аңларга;

-уку эшчәнлегенең уңышлылыгы (унышсызлылыгы) сәбәпләрен аңларга;

-аралашканда иптәшеңнең мотивларына һәм хисләренә ориентлашырга, үз-үзеңне тотышыңда мораль нормаларга һәм этик таләпләргә тотрыклы ияреге.



Документ создан в электронной форме. № 41 от 23.05.2024. Исполнитель: Сафин Ф.Н.
Страница 5 из 41. Страница создана: 23.05.2024 10:28

## УКЫТУНЫҢ ДҮРТЕНЧЕ ЕЛЫ

ПЛАНЛАШТЫРЫЛГАН ПРЕДМЕТ НӘТИҖӘЛӘРЕ

*Укучы өйрәнәчәк:*

- катлаулы булмаган монолог төзергә өйрәнү; геройлар һәм вакыйгаларга характеристика бирергә өйрәнү; укылган әсәрнең эчтәлеген план буенча ачарга өйрәнү; шигъри әсәрләрне сәнгатьле укырга өйрәнү; иптәшләре алдында кыска чыгышлар ясарга өйрәнү; дәреслек һәм фәнни-популяр әдәбият белән эшләргә өйрәнү; алган белемнәрне практикада кулланырга өйрәнү; укытучы ярдәмендә персонажларга бәя бирергә өйрәнү; төркемнәрдә үз фикерләрен дәлилли белергә өйрәнү.
- шигырьләрне сәнгатьле итеп уку;
- әсәрнең мәгънәви кисәкләре арасындагы бәйләнешләрне ачыклау, төп фикерне билгеләү һәм аны үз сүзләре белән әйтеп бирү;
- кыска күләмле әсәрләрнең эчтәлеген сөйләү;
- тылсымлы һәм хайваннар турындагы әкиятләрне аера белү;
- әсәрдәге төп геройга мөнәсәбәт белдерү;
- укылган әсәрдән чагыштыру, җанландыру, контрастны таба белү;
- 2–3 татар классигының исемен;
- 2–3 хәзерге заман язучысы яки шагыйренең исемен, язган әсәрләрен һәм аларның эчтәлеген;
- үзенә иң ошаган авторның берничә әсәрен;
- китапның төрле элементларына карап эчтәлеген билгеләү;
- сүзлекләрдән кирәкле мәгълүматны табу;
- әсәрләрнең геройларына характеристика бирү, чагыштырулар;
- авторның үз героена мөнәсәбәтен билгеләү;
- яраткан әдәби герое турында сөйли белү;
- дәреслектә дөрес ориентлашу, китапның элементларын төгәл билгеләү, авторын, исемен, эчтәлек язылган битен табу, иллюстрацияләр белән эшли белү;

**Укучы үзләштерү мөмкинлеге алачак**:

- катлаулы булмаган монолог төзи белү; геройлар һәм вакыйгаларга характеристика бирү; укылган әсәрнең эчтәлеген план буенча ачу; шигъри әсәрләрне сәнгатьле укый белү; иптәшләре алдында кыска чыгышлар ясау; дәреслек һәм фәнни-популяр әдәбият белән эшләргә күнегү; алган белемнәрне практикада куллана белү; укытучы ярдәмендә персонажларга бәя бирә белү; төркемнәрдә үз фикерләрен дәлилли белү.
- тематик, монографик әсәрләр җыентыклары төзи белү;
- төрле авторларның 6–8 әсәрен яттан белү;
- мөстәкыйль рәвештә китаплар сайлый белү, китап элементлары буенча аның эчтәлеген ачыклау;
- сүзлекләр белән мөстәкыйль эшләү;
- аңлап, йөгерек уку күнекмәләре булдыру;
- текстның темасын, төп фикерен табу, текстны мәгънәви кисәкләргә бүлү, текстның планын төзү, тулы һәм кыскача эчтәлекне бирә белүләренә ирешү;
- фольклор әсәрләрен тану, автор әсәрләре белән уртаклыгын, аермасын билгеләү;



Документ создан в электронной форме. № 41 от 23.05.2024. Исполнитель: Сафин Ф.Н.
Страница 6 из 41. Страница создана: 23.05.2024 10:28
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

- әсәрдәге геройлар турында үз фикерләрен әйтә белүләренә ирешү, геройларның характерын ачыклау, чагыштыру;
- сайлап алып, әсәрне яки бер өзекне яттан өйрәнү; ныгыту;
- дәреслектә оста ориентлашу;
- әсәрдән өзекләр китереп, аннотацияләр язу;
- уку елында өйрәнелгән әдәби әсәрләрнең исемен, авторын, эчтәлеген;
- 1–2 балалар журналын, аның бүлекләрен;
- теге яки бу авторларның китапларын (бирелгән исемлек буенча, чыгыш әзерләү өчен) мөстәкыйль рәвештә китапханәдә сайлый белү, китап элементлары буенча аның эчтәлеген ачыклау;
- сайланган әсәрләрне мөстәкыйль уку.
- әдәбиятны халыкның милли – мәдәни байлыгы, тормышны танып белүнең төп чарасы, милли һәм дөньви мәдәниятның бер чагылышы, әхлакый кыйммәтләрне һәм традицияләрне саклау чарасы буларак аңлау, шәхси үсеш өчен туган телдә нәфис әдәбит укуның кирәклеген аңлау, дөньяви белемнәрне, милли тарих һәм мәдәният турында белемнәрне арттыру үз-үзеңне һәм дөньяны танып белү өчен туган телдә даими уку кирәклеген аңлау,явызлык һәм яхшылык, әхлаклелек турында беренчел күзаллау булдыру; укуның төрләрен куллану (танышу, өйрәнү, сайлап уку, эзләнеп уку), эчтәлекне аңлап уку, бәя бирү, төрле текстларны куллану, фикер алуда катнашу, геройларга бәя бирү, белем алуны дәвам итү өчен зарур уку техникасын үзләштерү, әдәби, фәнни-популяр һәм уку текстларын үзгәртү, анализлау күнекмәләрен булдыру.

**Тыңлау (аудирование)**

Бу бүлектә укучы:
- ишеткән сөйләүне кабул итәргә (әңгәмәдәшеңнең фикерләрен, төрле текстларны укыганда тыңлый белә);
- сөйләм барышында әйтелгән фикерне аңларга;
- ишеткән әсәрнең эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә;
- вакыйгаларның эзлеклелеген билгеләргә өйрәнә.

Укучы сөйләмдә куелган максатны аңлый алу, дөрес, фәнни яктан танып-белү, әдәби әсәрләрне тыңлаганнан соң сораулар куя белү таләп итү мөмкинлеге ала.

**Уку. Кычкырып уку**

Бу бүлектә укучы:
- иҗекләп укудан әкренләп йөгерек, аңлап, сүзләп укуга күчергә;
- уку тизлеген даими рәвештә арттыра барырга;
- аны текстның мәгънәсен тулы күләмдә аңларлык дәрәҗәгә җиткерергә;
- укыганда орфоэпик һәм интонацион нормаларны сакларга;
- җөмләләрне укыганда тыныш билгеләрен интонация белән аера белергә өйрәнә.
- Укучы төрле төрдәге һәм типтагы текстларның мәгънә үзенчәлекләрен аңлау, аларны интонация ярдәмендә бирү мөмкинлеге ала .

**Эчтән уку**

Бу бүлектә укучы:
- яшь үзенчәлекләренә туры килгән күләмдәге һәм жанрдагы әсәрләрне эчтән укыганда мәгънәсен аңлап җиткерергә;
- уку төрләрен билгеләргә (өйрәнә, таныша, карап чыга, сайлап укый);
- тексттан тиешле мәгълүматны таба белергә өйрәнә.



Документ создан в электронной форме. № 41 от 23.05.2024. Исполнитель: Сафин Ф.Н.
Страница 7 из 41. Страница создана: 23.05.2024 10:28

- Укучы актлар, тасвирлау, өстәмә фикерләр белән тулыландырып уку бирү мөмкинлеге ала.

**Төрле стильдәге текстлар белән эш**

Бу бүлектә укучы:

- төрле стильдәге – әдәби, дәреслек, фәнни-популяр текстлар турында гомуми күзалларга;
- аларны чагыштыра белергә;
- бу төр текстларның максатларын билгеләргә;
- текстның темасын, төп фикерен, төзелешен ачыкларга;
- текстны мәгънәле кисәкләргә бүлергә, аларны исемләргә;
- фольклор текстының үзенчәлекләрен табарга;
- текстны төрле җөмләләр тезмәсеннән гамәли аерырга;
- әсәрнең исеменә һәм бизәлешенә карап, эчтәлеге турында белергә;.
- төрле мәгълүмат белән эшләргә;
- текст буенча сорауларга җавап бирергә;
- тема буенча чыгыш ясарга;
- иптәшенең чыгышын тыңларга;
- әңгәмә вакытында, текстны кулланып, җавапларны тулыландыруда катнашырга өйрәнә.

Укучы төрле белешмә һәм иллюстратив-сәнгать материалларыннан файдалану мөмкинлеге ала.

**Библиографик культура**

Бу бүлектә укучы:

- сәнгатьнең бер төре буларак китап булуын;
- китап – кирәкле белемнәрнең чишмәсе икәнен;
- Россиядә һәм татарларда беренче китаплар, аларның басыла башлау тарихын;
- уку китабы, әдәби әсәр, белешмәлекләр турында;
- китап элементлары: эчтәлеге яки бүлекләр исемлеге, титул бите, аннотация, иллюстрацияләр турында;
- китапта бирелгән мәгълүмат төрен ачыкларга: фәнни, әдәби (тышкы билгеләренә һәм анда бирелгән белешмә-иллюстратив материал);
- китап типларын ачыкларга;
- әсәр, җыентык, сайланма әсәр, вакытлы матбугат, белешмәлекләр (сүзлек, энциклопедия) турында;
- бирелгән исемлек, картотека буенча китап сайлый белергә;
- алфавит каталогыннан файдаланырга өйрәнә.
- Укучы яшь үзенчәлекләренә туры килгән сүзлек һәм белешмә материалларны мөстәкыйль рәвештә куллана белү мөмкинлеге ала.

**Әдәби әсәр тексты белән эш**

Бу бүлектә укучы:

- әсәрнең исемен аның эчтәлегенә мөнәсәбәтле рәвештә аңларга;
- укытучы ярдәмендә әдәби әсәрнең сәнгати үзенчәлекләрен билгеләргә;
- халык авыз иҗаты әсәрләренең гомумкешелек әхлак кагыйдәләрен һәм кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләрен күрсәтүен ачыкларга;
- әсәр геройларының эш-гамәлләренә әхлак кагыйдәләре нормаларыннан чыгып бәя бирергә;



Документ создан в электронной форме. № 41 от 23.05.2024. Исполнитель: Сафин Ф.Н.
Страница 8 из 41. Страница создана: 23.05.2024 10:28
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

- Туган ил, Ватан төшенчәсен аңларга;
- Россия халыклары мисалында әдәбиятта төрле милләт халыкларының туган илгә мәхәббәте турында;
- төрле халыкларның фольклорында тема, идея, геройларның охшашлыгы турында;
- телнең сурәтләү чараларын кулланып, мөстәкыйль рәвештә текстны күз алдына китерергә;
- укытучы сораулары буенча, әсәрнең лексик үзенчәлекләрен истә тотып, эпизодларны бер-бер артлы искә төшерергә;
- иллюстрацияләр буенча эчтәлеген сөйләргә;
- сәнгатьлелек тудыру чараларын кулланып, бирелгән тексттагы геройга характеристика бирергә;
- әсәрдән геройны һәм вакыйгаларны характерлаган сүзләрне табарга;
- укытучы ярдәмендә катнашучыларның эш-гамәлләренең мотивларын билгеләргә;
- аларны анализларга;
- геройларның эш-гамәлләрен капма-каршылыгы яки охшашлыгы буенча чагыштырырга;
- текстны анализлау барышында автор билгеләмәләре, геройның исеме аша авторның аңа мөнәсәбәтен ачыкларга;
- әсәр героеның портретын, характерын аның эш-гамәлләре һәм сөйләме аша аңларга;
- әдәби әсәр эчтәлеген сөйләүнең төрләрен (тулы, сайлап, кыскача – төп фикерне әйтү);
- текстның эчтәлеген тулысынча сөйләргә;
- бирелгән өзектәге төп фикерне ачыкларга;
- кирәкле сүзләрне билгеләргә;
- исем кушарга;
- эпизодның эчтәлеген тулысынча сөйләргә;
- һәрбер өлешнең һәм текстның төп фикерен билгеләргә;
- һәр өлешкә һәм тулаем текстка исем кушарга;
- тексттагы җөмләләрне атарга;
- сорау җөмлә яки үзләре теләгән форма кулланып, план төзергә
- бирелгән өзек эчтәлеген сайлап сөйләргә;
- геройга характеристика бирергә  (кирәкле сүзләрне тексттан сайлау);
- вакыйга буенча урынны сурәтләргә (урынны сурәтләгән сүзләр, сүзтезмәләрне тексттан алып) өйрәнә.
- Укучы  төрле әсәрдәге охшаш ситуацияләрне, геройларны табу, чагыштыру мөмкинлеге ала.

**Уку материалы, фәнни-популяр һәм башка текстлар белән эш**

Бу бүлектә укучы:

- әсәрнең исемен аның эчтәлегенә бәйле рәвештә аңлатырга;
- уку, фәнни-популяр текстларның үзенчәлекләрен ачыклый белергә;
- риваять, легенда, мәсәл, миф, санамыш, әкият,  тизәйткеч, үртәвеч, такмаза, бәет кебек әсәрләрнең гомуми үзенчәлекләрен аңларга;
- текстларга гади анализ алымнары турында;
- сәбәп һәм нәтиҗә бердәмлеген ачыкларга өйрәнә.
- Укучы текстның төп фикерен, микротемаларны, төп һәм терәк сүзләрне табу; текстны кабат укыганда эшчәнлек алгоритмын төзү;терәк сүзләр, модель, схемаларга таянып, текстны кабат күздән кичерү; эчтәлекне тулысынча һәм кыскача сөйләү (төп фикерне билгеләү) бирү мөмкинлеге ала.



Документ создан в электронной форме. № 41 от 23.05.2024. Исполнитель: Сафин Ф.Н.
Страница 9 из 41. Страница создана: 23.05.2024 10:28
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

**Сөйләм (аралашу культурасы)**
Бу бүлектә укучы:
- сөйләм төре буларак диалог турында;
- диалогик сөйләмнең үзенчәлекләрен: сорауны аңларга, аларга җавап бирергә;
- текст буенча сораулар куярга;
- әңгәмәдәшеңне бүлдермичә тыңлый һәм тикшерелә торган мәсьәлә буенча әдәпле итеп үз фикереңне әйтә белергә (уку, фәнни, әдәби текст буенча);
- текстка һәм шәхси тәҗрибәгә нигезләнеп, текст турында үз фикереңне әйтергә;
- дәрестән тыш аралашу вакытында сөйләм әдәбе нормаларыннан тайпылмаска;
- фольклор әсәрләре нигезендә милли этикет үзенчәлекләре турында;
- сүзлек белән эшләргә (туры, күчерелмә, күпмәгънәле сүзләрне аерып алырга);
- сүзлек байлыгын тулыландырырга;
- сөйләм төре буларак монолог турында;
- автор текстына таянып, тәкъдим ителгән яки укытучы әйткән тема буенча зур булмаган текст (монолог) төзергә;
- сөйләмдә текстның төп фикерен чагылдырырга;
- фәнни-популяр һәм әдәби әсәрләрнең үзенчәлеген искә алып, укылган яки ишеткән текстның эчтәлеген төгәл сөйләп бирергә;
- көндәлек тормыштан, әдәби әсәрләрдән, сынлы сәнгать әсәрләреннән алынган тәэсирләрне тасвирлый белергә, фикерләргә, хикәяләү аша бирергә;
- чыгышын дөрес планлаштырырга;
- монологик сөйләмнең үзенчәлекләрен искә алып, синоним, антоним, чагыштыруларны урынлы кулланырга өйрәнә.
- Укучы укылган әсәрнең дәвамы буларак, телдән сочинение, рәсем яки бирелгән тема буенча кечкенә хикәя төзү мөмкинлеге ала.

**Язма сөйләм культурасы**
Бу бүлектә укучы:
- язма сөйләм нормаларын;
- эчтәлекнең әсәр исеменә туры килүен (тема чагылышы, геройларның характеры, вакыйга барган урын);
- язма сөйләмдә телнең сәнгати сурәтләү чараларын: синоним, антоним, чагыштыруларны куллана белергә өйрәнә.
- Укучы бирелгән тема буенча хикәя, бәяләмә төзү мөмкинлеге ала.
- Балалар китабы белән эш
- Бу бүлектә укучы:
- Россиядә яшәүче төрле милләт халыкларының авыз иҗаты әсәрләрен;
- XIX–XX гасырда яшәгән классик язучыларның (шул исәптән балалар язучыларының да) әсәрләрен;
- Чит ил һәм хәзерге көн язучыларының кече яшьтәге мәктәп баласы аңлый алырлык әсәрләрен;
- төрле китаплар (тарихи, маҗаралы, фантастик, фәнни-популяр басмалар, белешмәлекләр, энциклопедияләр) һәм балалар вакытлы матбугаты турында;
- юмористик әсәрләр турында өйрәнә.
- Укучы балаларга тәкъдим ителә торган төп темалар: төрле халыкларның авыз иҗаты, Туган ил, табигать, балалар, җәнлекләр, яхшылык һәм яманлык аера белү мөмкинлеге ала.

**Әдәби әсәрләрне гамәли үзләштерү**
Бу бүлектә укучы:


Документ создан в электронной форме. № 41 от 23.05.2024. Исполнитель: Сафин Ф.Н.
Страница 10 из 41. Страница создана: 23.05.2024 10:28
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

- укытучы ярдәмендә әдәби тексттан сәнгатьлелек чараларын: синоним, антоним, эпитет, чагыштыру, метафора, гиперболаларны табырга һәм аларның әһәмиятен билгеләргә;
- әдәби әсәр, әдәби образ, сүз сәнгате, автор (сөйләүче), сюжет, тема; әсәр герое: портреты, сөйләме, эш-гамәлләре, фикерләре; авторның әсәр героена мөнәсәбәте төшенчәләрен;
- әсәрнең төзелеш үзенчәлекләрен;
- сурәтләргә (пейзаж, портрет, интерьер);
- фикер йөртергә;
- геройның монологы һәм диалогы, композиция үзенчәлекләре турында күзалларга;
- чәчмә һәм тезмә сөйләмне танырга, аерырга;
- тезмә сөйләмнең үзенчәлекләрен (ритм, рифма) билгеләргә;
- фольклор һәм автор әсәрләрен аерырга;
- әсәрләрнең жанр төрлелеге турында;
- фольклор формасы буларак мәкальләр, әйтемнәр, табышмаклар турында;
- аларны таный, аера, төп фикерен билгеләргә;
- әкиятләр (хайваннар турында, тормыш-көнкүреш, тылсымлы) турында;
- әкиятләрнең әдәби үзенчәлеге, тел байлыгы, төзелеше турында;
- автор әкиятләре турында өйрәнә.
- Укучы хикәя, шигырь, мәсәл жанрлары турында гомуми күзаллаулар, төзелеш үзенчәлекләре, сәнгати чаралары турында гомуми күзаллау мөмкинлеге ала.

## УКЫТУНЫҢ БЕРЕНЧЕ ЕЛЫ

### УКЫТУ ПРЕДМЕТЫНЫҢ ЭЧТӘЛЕГЕ

**Әлифба.**

“Әлифба” китабы. Сөйләм. Кешеләрнең әйтеп һәм язып сөйләшүләрен гому¬ми күзаллау. Татар халык әкияте “Өч кыз”.

Сөйләм. График схемалар ярдәмендә сөйләмне җөмләләргә, җөмләне сүзләргә аеру. Җөмлә һәм сүз. Җөмлә моделе. Сүз турында башлангыч төшенчәләр. А. Алиш “Куян кызы” әкияте.Автор бирергә теләгән картинаны күзаллау. Г. Тукай “Эшкә өндәү”. Предметны белдерүче, гомумиләштерүче сүзләр.Хәрәкәтне һәм билгене белдерүче сүзләр. Ярдәмлек сүз. Хәреф – авазның язудагы тамгасы, татар телендә авазлар һәм хәрефләр. Сузык авазлар. Нечкә һәм калын сузык авазларны аеру. [а], [ә] авазлары. А, а; Ә, ә хәрефләре. Сүзләрнең аваз моделе.

[ы], [э]авазлары. Ы, ы; Э, э (е) хәрефләре. Сүзнең аваз һәм хәреф схемасы.

[и] авазы. И, и хәрефләре. Сүзнең аваз һәм хәреф схемасы.

[у], [ү] авазлары. У, у; Ү, ү хәрефләре. Иҗекләр. Сузык аваздан торган һәм сузык аваздан баш¬ланган иҗекләр. Ау, уа иҗекләре.

[о]авазы. О, о хәрефләре. Сүзләрне иҗек һәм аваз¬ларга таркату. Кушылмадан торган һәм кушылма авазлардан башланган иҗекләр. Татар халык әкияте “Камыр батыр”.

[ө] авазы. Ө, ө хәрефләре. Г. Тукай “Торна белән Төлке”.



Документ создан в электронной форме. № 41 от 23.05.2024. Исполнитель: Сафин Ф.Н.
Страница 11 из 41. Страница создана: 23.05.2024 10:28

Сузык авазлар таблицасы. Сузык һәм тартык авазлар, нечкә һәм калын сузык авазларны аеру.Тартык авазлар. Яңгырау һәм саңгырау тартыклар. Сонор тартыклар. Сонор [н] авазы. Н, н хәрефләре.Сонор [л] авазы. Л, л хәрефләре. Кушылмадан торган һәм кушылма авазлардан башланган иҗекләр. Г. Гыйльманов ”Шигъри әлифба”

Сонор [м] авазы. М, м хәрефләре, шул хәрефләр кергән сүзләрне уку.

Сонор [р] авазы. Р, р хәрефләре. Балалар китабы белән эшләү. Китапны саклап тоту күнекмәләре булдыру.Сүз уртасында, сүз ахырында сонор [й] авазы. Й, й хәрефләре

[н] авазы, ң хәрефе. Ш. Галиев “Витаминлы хәрефләр” Эчтән укый белергә күнектерү.

Ике аваз белдерүче хәрефләр. [йа], [йә]авазлары. Я, я хәрефләре. Р. Миңнуллин “Саный беләм”. [йу], [йү], [йы], [йэ] авазлары. Ю, ю; Е, е хәрефләре.

Парлы яңгырау һәм саңгырау тартыклар.[д], [д'] авазлары. Д, д хәрефләре. Ә. Бикчәнтәева “Дәү әнием”. [т], [т'] авазлары. Т, т хәрефләре. Г. Тукай “Туган тел”. Эчтән укый белергә күнектерү.[з], [з'] авазлары. З, з хәрефләре.

[с], [с'] авазлары. С, с хәрефләре. Әсәрне тыңлап, аңлы кабул итү. М. Җәлил “Карак песи”.

[г], [г'] авазлары. Г, г хәрефләре. Текст эчтәлеген сайлап алып сөйләү. Һ. Такташ “Тәүфыйклы песи”.

Укылган әсәргә анализ ясау. [к], [к'] авазлары. К, к хәрефләр.е

Ирен-ирен [w] һәм ирен-теш [в] авазлары. В, в хәрефләре..

[ф], [ф'] авазлары. Ф, ф хәрефләре. Әсәрнең төп эчтәлеге. А. Алиш “Сертотмас үрдәк”

[б], [б'] авазлары. Б, б хәрефләре. Р. Миңнуллин “Сабантуй” Дәрестән тыш эшчәнлекне оештыру, өй, мәктәп китапханәләреннән файдалану.

Уку техникасын үстерү. [п], [п'] авазлары. П, п хәрефләре

[ж] авазы. Ж, ж хәрефләре. Сәнгатьле уку күнекмәләре формалаштыру (интонация, тон, темп саклап кычкырып уку).

[ш] авазы. Ш, ш хәрефләре. Әкиятнең эчтәлеге. “Ташбака белән Куян” әкияте. Укылган әсәргә анализ ясау.

[җ], [җ'] авазлары. Җ, җ хәрефләре Сәнгатьле уку күнекмәләре формалаштыру ( интонация, темп саклап кычкырып уку).

[ч], [ч'] авазлары. Ч, ч хәрефләре. Укыганны кабатлап сөйләү. “Яшелчә бакчасы” тексты

Парсыз саңгырау тартыклар. [х], [х'] авазлары. Х, х хәрефләре. Әсәрне яки өзекне яттан уку. Х. Халиков “Хәзинә”

[һ], [һ'] авазлары. Һ, һ хәрефләре. Х. Халиков “Шаулама”

[йо] авазы. Ё, ё хәрефләре. Рәсем буенча хикәя Якташ очучыбыз (Вәлиев Гәрәфетдин) турында әңгәмә.

[щ] авазы. Щ, щ хәрефләре.

[ц] авазы. Ц, ц хәрефләре Укылган әсәргә анализ ясау.

ь, ъ – нечкәлек һәм калынлык, аеру билгеләре. Р. Бәшәр “Туган җир”. Эчтән укый белергә күнектерү.

Алфавит. Алфавит каталогыннан файдалану. Ш. Галиев “Телевизор булды баш” Сәнгатьле уку күнекмәләре формалаштыру (интонация, тон, темп саклап кычкырып уку).

Сәнгатьнең бер төре буларак китап. Уку китабы, әдәби әсәр, белешмәлекләр. Әсәр геройлары һәм вакыйгалар барышы. Россия халыклары әдәбияты. Й.Шәрәпова “Батыр”.

Китап элементлары: эчтәлеге яки бүлекләр исемлеге, титул бите, иллюстрацияләр Яшь үзенчәлекләренә туры килгән сүзлек һәм белешмә материалларны мөстәкыйль рәвештә куллана белү. А. Хәлим “Биктырыш җыры” Уку техникасын үстерү.

**Әдәби уку.**



Документ создан в электронной форме. № 41 от 23.05.2024. Исполнитель: Сафин Ф.Н.
Страница 12 из 41. Страница создана: 23.05.2024 10:28

“Әдәби уку” китабы.  Халык авыз иҗаты турында  гомуми кузаллау. Авторның  булмавы. Аптыраткыч әкиятләр сере. Әкиятләр турында гомуми күзаллау.

Татар халык иҗатында кече фольклор жанрлары. Сюжет куелышы. Тылсымлы дөньядагы предметлар, әкияти төсләр, тылсымлы булышчылар.

Гамәли-уен характерындагы кече жанр әсәрләре. Фольклор әсәрләрен аеру. Табышмак ничек төзелә. Санамыш серләре. Борынгы  санамышлар.

Яшь үзенчәлекләренә туры килгән сүзлек һәм белешмә материалларны мөстәкыйль рәвештә куллана белү. Телдән сөйләм. Эндәшләр. Р. Газизов “Уйныйбыз”. Әсәрне яки өзекне яттан уку.

Тизәйткечләр. Төрле жанрдагы әсәрләрне гамәли аеру Охшаш яңгырашлы сүзләр.        М. Галиев “Кайтаваз”.

Рифма һәм шигырь мәгънәсе. Р. Газизов “Беләсезме?”

Шаян шигырьләр. Л. Лерон “Буталмышлар илендә” Уку техникасын үстерү.

Әйләнмәле һәм чылбыр әкиятләре. Чылбыр рәвешендә укыганда, үз урыныңны белеп чират буенча уку.. Тылсымлы әкиятләрдән аермалы яклары. Әкиятләрдә проблемалар, үгет-нәсыйхәт, юмор хисе.

Яңгыравык шигырьләр. Ф. Яруллин “Черкиләр җыры”. Иллюстрация сәнгате.

Хикәянең исеме. Әсәр геройларына карата үз фикереңне белдерү. Әсәр исеменең төп мәгънә, эчтәлек белән туры килүе. Хикәя герое. Геройларның характерына чагыштырма анализ. Прозада  сүзләрнең үзенчәлекле яңгырашы.  Э. Шәрифуллина “Бәйрәм ашы – кара-каршы”

Шигырь. Дөньяны шагыйрьләр күзлегеннән чыгып танып белү: шагыйрьнең матурлыкны тоя белергә өйрәтүе. Поэзиядә яңгыравык сүзләр.

Х. Халиков “Әллә ул да белә микән?”

Балалар шигырьләре. Р. Миңнуллин “Үзебез генә калгач”. Ш. Галиев “Шауламагыз, әти йоклый”.

Санамыш, тизәйткеч, үртәвеч. Шигырьдә юмор хисе. Б. Заходер “Өтерне кайда куярга?”

Язучы фантазиясе. Р. Кутуй “Төнге әкият”. Автор һәм халык әкиятләрендә сюжет-композиция охшашлыгы, яңа мәгънәви төсмерләр бирү.

Дөньяны кем ничек күрә? Сурәтләнгән вакыйгаларга карата автор фикере. Чагыштыру, җанландыру кебек гади әдәби алымнар. Р. Миңнуллин “Шүрәлесез урман”.    Х. Халиков “Әгәр күрә белсәгез”

Шагыйрь нәрсә күрә һәм ишетә? Автор теленең кабатланмас матурлыгы. Кеше һәм табигать бергәлеге.Шигырьләрдә

әдәби сурәтләү чаралары (чагыштыру, җанландыру). Р. Вәлиева “Кыңгырау чәчәк”.

Жанрлар турында гомуми кузаллау.  Такмазалар, уйдырмалар, үртәвечләр. Х. Халиков “Көймәче мәче”. Бишек җырлары. Р. Харис “Сине көтә тыныч таң”.  Шагыйрьләр күзлегеннән караганда дөнья матурлыгы.

Арадаш аттестация(тест)

Автор әсәрләрендә һәм халык әкиятләрендәге сюжет кулланылышы (капма-каршы ике дөнья, булышчылыр, тылсымлы төсләр). Хаталар өстендә эш. Әдәби әкиятләр. М. Әгъләмов “Килсен безгә әкият”.

Әсәрнең герое турында күзаллау булдыру.Әсәрдәге геройларга карата үз фикерен белдерү. Х. Туфан “Юкмыш бабай малае”. Ике образны чагыштырып сөйли белү.

Тезмә әсәр үзенчәлеге: рифма. Рифмалашкан сүзләр. Л. Лерон “Буталмыш әкият”. “Шүрәле” – халык әкияте.

Шагыйрьләр иҗат иткән дөнья белән чынбарлык арасындагы охшаш һәм аермалы яклар. Рифмалашкан сүзләр.  “Әннәгизә-генәем”.

Автор әсәрләрендә һәм халык авыз иҗатында охшашлык. Бертуган Гриммнар. “Дөньяда булмаган әкият”.

Әдәби әсәрләрнең башка сәнгать әсәрләре белән бәйләнеше. Рәссам нәрсә күрә?

Р. Фәйзуллин  “Табигать кочагында”.



Документ создан в электронной форме. № 41 от 23.05.2024. Исполнитель: Сафин Ф.Н.
Страница 13 из 41. Страница создана: 23.05.2024 10:28
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

**Тематик планлаштыру**

| № | Бүлек һәм дәрес темасы | Сәг. саны |
|---|---|---|
| **Халык авыз иҗаты әсәрләре-2 сәгать** | | |
| 1 | Сөйләм. Җөмлә. Сүз. ”Өч кыз”, “Куян кызы” әкиятләре. | 1 |
| 2 | Предметларны, хәрәкәтне, билгене белдерүче сүзләр. Тормыш-көнкүреш әкиятләре. | 1 |
| **Библиографик культура - 4 сәгать** | | |
| 3 | Ярдәмлек һәм җөмлә төзүче сүзләр. Китапның төп элементларын аеру. | 1 |
| 4 | [а],[ә],[ы], [э] сузыклары.<br>А,а,Ә,ә,Ы,ы,Э.э(е) хәрефләре. Х.Халиков “Энҗе чәчәк”. | 1 |
| 5 | [и],[у],[ү] авазлары. И,и, У,у,Ү, ү хәрефләре. Ф.Мөслимова “Хәйләкәр каләм”. | 1 |
| 6 | [о],[ө] авазлары. О,о,Ө,ө хәрефләре. Йолдыз “Урынсызга әрләмә”. | 1 |
| **Халык авыз иҗаты әсәрләре- 1 сәгать** | | |
| 7 | **Парсыз сонор тартык авазлар [н],[л] тартыклары. Н,н,Л,л хәрефләре.** | 1 |
| **Уку, сөйләү, тыңлау күнекмәләре формалаштыру -1 сәгать** | | |
| 8 | [м],[р] тартыклары.<br>М,м, Р, р хәрефләре. Ф.Яруллин “Саескан”, “Хыялый чебеш”, “Сабантуй”. | 1 |
| **Әдәби жанрлар – 9 сәгать** | | |
| 9 | [й],[ң] тартыклары. Й,й.ң хәрефләре. Ф.Зыятдинова “Мин андый малай түгел!” | 1 |
| 10 | **Сүз башында һәм сүз уртасында \|й] авазы. [йа], [йә] авазлары. Я, я хәрефләре.Хикәя.Хикәянең исеме.** | 1 |
| 11 | **[йу], [йү] авазлары. Ю, ю хәрефләре. Ш.Галиев “Шәвәли сәгате”, “Шәвәли сере”** | 1 |
| 12 | **[йы], [йә] авазлары. Е, е хәрефләре.** В Хәйруллина “Сүзне сүз ашаган”. | 1 |
| 13 | **Яңгырау һәм саңгырау парлары булган тартыклар.**<br>[д],[т] авазлары. Д,д,Т,т хәрефләре. Х.Халиков “Тузганак”. | 1 |
| 14 | [з],[с] авазлары. З.з,С,с хәрефләре. Ф.Яруллин “Черкиләр җыры”. Р | 1 |
| 15 | г],[к] авазлары. Г,г,К,к хәрефләре. Х.Халиков “Каен җиләге”, “Песи үләне”. | 1 |
| 16 | [в],[w],[ф] авазлары. В,в,ф,ф хәрефләре. | 1 |
| 17 | [б],[п] авазлары. Б,б,П,п хәрефләре. | 1 |
| **Автор әсәрләре-1 сәгать** | | |



Документ создан в электронной форме. № 41 от 23.05.2024. Исполнитель: Сафин Ф.Н.
Страница 14 из 41. Страница создана: 23.05.2024 10:28
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| | | |
|---|---|---|
| 18 | [ж],[ш] авазлары.Ж,ж,Ш,ш хәрефләре. | 1 |
| **Халык авыз иҗаты әсәрләре-1 сәгать** | | |
| 19 | [җ],[ч] авазлары. Җ,җ,Ч,ч хәрефләре.  ”.<br>В Хәйруллина “Сакчы Шүрәле”. | 1 |
| **Уку, сөйләү, тыңлау күнекмәләре формалаштыру -1 сәгать** | | |
| 20 | Х,х,Һ,һ хәрефләре. Р.Бәшәр “Авазлар”. Сәнгатьле уку күнекмәләре формалаштыру (интонация, тон, темп саклап кычкырып уку). | 1 |
| **Халык авыз иҗаты әсәрләре-1 сәгать** | | |
| 21 | щ, ц авазлары. Щ,щ,Ц,ц хәрефләре. Автор әкиятләре. Бертуган Гриммнар “Дөньяда булмаган әкият”. | 1 |
| **Автор әсәрләре-1 сәгать** | | |
| 22 | **Аеру билгеләре булып торган ь һәм ъ  соң [й] авазы.**<br>йо авазы. Г.Тукай “Туган тел”. | 1 |
| **Библиографик культура - 4 сәгать** | | |
| 23 | Н.Исәнбәт “Өч матур сүз | 1 |
| 24 | Аралашу культурасы. Ә.Кари “Кыш” | 1 |
| 25 | Аңлап һәм сәнгатьле уку күнекмәләрен үстерү. И.Туктар “Кышкы урманда | 1 |
| 26 | Г.Тукай “Безнең гаилә”, М.Гафури “Әби белән онык” | 1 |
| **Уку, сөйләү, тыңлау күнекмәләре формалаштыру -1 сәгать** | | |
| 27 | И.Туктар “Авыраяк”, Х.Шабанов “Кадерлә син китапны” | 1 |
| **Әдәби жанрлар-1 сәгать** | | |
| 28 | Шигырь. Рифма белән танышу: аны сиземли, таба, куллана белергә күнектерү. А.Алиш “Эшче абый”, Г.Тукай “Эшкә өндәү”. | 1 |
| **Уку, сөйләү, тыңлау күнекмәләре формалаштыру -2 сәгать** | | |
| 29 | Аңлап һәм сәнгатьле уку күнекмәләре булдыру. М.Хәсәнов “Басма”, М.Җәлил | 1 |



Документ создан в электронной форме. № 41 от 23.05.2024. Исполнитель: Сафин Ф.Н.
Страница 15 из 41. Страница создана: 23.05.2024 10:28
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| | | |
|---|---|---|
| | "Бакчада-өмәдә" | |
| 30 | Укуга карата таләпләрне төгәл үтәү: кычкырып укуның дөреслеге, сәнгатьлелеге, укуның тизлеге. Г.Тукай "Карлыгач" | 1 |
| **Халык авыз иҗаты әсәрләре-3 сәгать** | | |
| 31 | Россия халыклары әкиятләре.<br>Татар халык җырлары "Әпипә", Ай былбылым". | 1 |
| 32 | Тылсымлы әкиятләр. Өч кыз. | 1 |
| 33 | Г.Тукай "Су анасы". | 1 |
| Барлыгы: 33 с. | | |

## УКЫТУНЫҢ ИКЕНЧЕ ЕЛЫ

### УКЫТУ ПРЕДМЕТЫНЫҢ ЭЧТӘЛЕГЕ

Баланың китап укучы буларак тәҗрибәсен үстерү. Хайваннар турындагы әкиятләр белән бергә тылсымлы әкиятләр өстендә дә эш алып бару. Әсәрнең исемен, геройларның үз-үзен тотышын, эш-гамәлләрен портретларын, исемнәрен, сөйләмнәрен анализларга өйрәнү.

